# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш), 2010, № 7 (II өлеш), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативлар исәпләү методикасы**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында" 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

Методика җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү өчен кирәкле чаралар күләмен билгеләүнең методологик нигезләрен урнаштыруга юнәлдерелә.

Норматив (әлеге Методика максатларында) – муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында төзелә торган балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен (алга таба – муниципаль комиссияләр) төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары ихтыяҗларының исәп-хисап күрсәткече, ул Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең даими штат нигезендә эшләүче бер җаваплы секретарена, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең балигъ булмаганнар белән эшләү буенча даими штат нигезендә эшләүче бер белгеченә (алга таба – муниципаль комиссия белгечләре) исәпләгәндә бюджет чараларында күрсәтелә.

## 2. Муниципаль комиссиянең бер белгеченә исәпләгәндә муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру чыгымнарының нормативларын билгеләү

Муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегенең муниципаль комиссиясенең бер белгеченә чыгымнарны исәпләү (Hi) түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Hi = Zi + Ni + Mi,$$

монда:

Hi – муниципаль комиссиянең бер белгеченә исәпләгәндә Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органында муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен норматив;

Zi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссиянең бер белгече хезмәте өчен түләү чыгымнары, алар түбәндәге вазыйфа буенча хезмәт өчен түләү шартларыннан чыгып исәпләнгән:

"муниципаль комиссиянең җаваплы секретаре өчен – муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитеты (башкарма комитеты аппараты) идарәсенең, бүлегенең, секторының, бүтән структур бүлекчәсенең төп белгече", Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген хезмәт өчен түләүнең тиешле төркеменә кертүне исәпкә алып;

"муниципаль комиссиянең балигъ булмаганнар белән эшләү буенча белгече өчен – муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитеты (башкарма комитеты аппараты) идарәсенең, бүлегенең, секторының, бүтән структур бүлекчәсенең әйдәүче белгече", Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген хезмәт өчен түләүнең тиешле төркеменә кертүне исәпкә алып;

Ni – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлеге муниципаль комиссиясенең бер белгече хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә өстәп исәпләнгән суммалар чыгымнары;

Mi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлеге муниципаль комиссиясенең бер белгеченә исәпләгәндә матди тәэминат чыгымнары.

Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссиянең бер белгече хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә өстәп исәпләнгән суммалар чыгымнарын исәпләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Ni = Zi \times Снз,$$

монда Снз – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә өстәп исәпләнгән суммалар ставкасы.

Муниципаль комиссиянең бер белгеченә исәпләгәндә матди тәэминат чыгымнарына, Татарстан Республикасы бюджетының керем өлеше мөмкинлекләреннән чыгып, индекс-дефляторлар куллануга бәйле рәвештә чыгым материалларын сатып алуга, командировкалар өчен, коммуналь хезмәт күрсәтүләр һәм элемтә хезмәте күрсәтүләре өчен түләүгә тотыла торган чыгымнар керә.

### 3. Муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләү

Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Ci = Hi x Чi,

монда:

Ci – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссияләрне төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр күләме;

Чi – Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә муниципаль комиссия белгечләре саны.".

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 17 декабре
№ 84-ТРЗ